Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Васильевка авыл Советы
КАРАРЫ

11 декабрь 2020 ел № 8

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 49 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 нче номерлы карары нигезендә

Васильевка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 49 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының 2018 елның 5 декабрь 51 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Уникенче төркем хезмәт хакы, сум |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 15753,0 |
| Авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 15293,0 |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме”

| Вазыйфаның исеме | Уникенче төркем хезмәт өчен түләү буенча авыл җирлекләрендә айлык акчалата түләү күләме, сум |
|---|---|
| Башлык | 15759,0 |
| Башлык урынбасары | 11499,0 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Васильевка авылы, Үзәк урамы, 26 йорт, Улаклы Чишмә авылы, Үзәк урамы, 32а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Васильевка авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Васильевка авыл җирлеге
Башлыгы Ш.М. Касыймуллин